**Татарстан Республикасы  Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. №36 «28» август 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 2009 елның 26 мартындагы 3 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (30.05.2013 №15, 15.06.2015 №16 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 68 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2018  елның 03 июлендәге 189-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә

**Татарстан Республикасы  Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 2009 елның  мартындагы 3 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәгә (30.05.2013  №15,  15.06.2015 №16  карарлар редакциясендә) «ябык» сүзен «гавами булмаган» сүзе белән алмаштырып, 4 пунктның 8 пунктчасында үзгәреш кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Р.А. Галиева